Республика Татарстан
Глава Абалачевского сельского
поселения Менделеевского
муниципального района
ул. Центральная д. 35, помещ.1, д. Абалачи
Менделеевский район, 423657

Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы
Абалач авыл җирлеге
Башлыгы
Үзәк урамы, 35, бина 1, Абалач авылы,
Менделеевск районы, 423657

тел./факс (85549)3-65-49 Email: Abal.Men@tatar.ru

10.11. 2023 ел № 2

Постановление Карар

2024 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы «Абалач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә,

Карар бирәм:

1. 2023 елның 20 ноябре 16.00 сәг.Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2023 елның 20 ноябре 17.00 сәг.Абалач авыл җирлегенең Абалач авылында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. Җыеннарның барлык этапларын уздыру урыны итеп Менделеевск районы, Абалач авылы, Үзәк урам 35 йорт адресы буенча урнашкан Абалач авыл мәдәният йортын билгеләргә.

Абалач авылында яшәүчеләрнең исемлеген җыеннар этапларына бүлү территориаль билге буенча түбәндәге тәртиптә башкарырга:

Беренче этап: Үзәк урам, 1А йортыннан 42 йортка кадәр

Икенче этап: Үзәк урам, 43йорттан 110 йортка кадәр, Елга аръягы урамы 2 йорттан 23 йортка кадәр

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«2024 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлегенең Тагай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә билгеләргә, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендәге студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы?

- Абалач авылы өчен балалар мәйданчыгы сатып алу
- Абалач авылы өчен балалар мәйданчыгы урнаштыру
- Абалач авылында җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, триммер өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш өчен түләү)
- "Беларус МТЗ-82" тракторына техник хезмәт күрсәтү
- Абалач авылында скважина өчен су насосы сатып алу (1 данә.)
- Абалач авылында Үзәк һәм Елга аръягы урамнары буенча авыл эчендәге юлларны карап тоту (кышкы чорда кардан чистарту)
- МТЗ 82 тракторы өчен фронталь йөк төягеч сатып алу
- Абалач авылында балалар мәйданчыгы территориясендә койма ясау һәм монтажлау

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында - www.mendeleevsk.tatar.ru «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә

Абалач авыл җирлеге башлыгы Р.Н. Сиражетдинов